**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы**

# КАРАРЫ

**10 ноябрь 2021 ел** **№ 4**

**«Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Филипповка поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 22 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Филипповка поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Филипповка поселогы, Октябрьская урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында үткәрергә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлар, туендыручысын югалткан күп балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Филипповка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгынга каршы савыт, рукавлар, стволлар, переходниклар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Филипповка поселогының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Ошторма Юмья авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы С.В. Тимофеев